СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.08.2020 п.г.т. Алексеевское № 247

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск ш.т.б. җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 29 гыйнварындагы 108 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Уставы нигезендә, 2020 елның 03 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен (киңәшләрен) исәпкә алып,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск ш.т.б. Советының 2011 елның 29 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, аерым алганда, Алексеевск ш.т.б. шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1). Алексеевск ш.т.б. үзәк өлешендә, Павелкиң ур., 33 й. һәм Казаков ур., 1Б й. ОД-5 территориаль зонасының бер өлеше (Җитештерү-эшлекле территорияләр) һәм ПК-1 территориаль зонасын (Җитештерү һәм коммуналь-склад объектлары зонасы) 0,74 га мәйданлы торак-2 территориаль зонасына (аз катлы һәм урта катлы торак йортларда төзелеш зонасы) үзгәртергә (1 нче кушымта).

2). Алексеевск ш.т.б. төньяк-көнчыгыш өлешендә, Юлчылар ур., з/у 1Б; Юлчылар ур., з/у 1В һәм Юлчылар ур., з/у 1Г өлешендә Р-1 территориаль зонасының бер өлешен (гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасын) 5,5 га гомуми мәйдандагы Ж-2 территориаль зонасына (аз катлы һәм урта катлы торак йортлар белән төзелеш зонасы) үзгәртергә. (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Алексеевск шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары О.В. Зубриловага йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**

2020 елның 11 августындагы
247 номерлы Алексеевск
шәһәр җирлеге Советы карарына
1 нче кушымта



2020 елның 11 августындагы
247 номерлы Алексеевск
шәһәр җирлеге Советы карарына
2 нче кушымта

